РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2023 Буа шәһәре № 273 Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Башкарма комитетына кергән
гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау
тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» һәм Буа муниципаль районы Советында гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен анализлауның бердәм тәртибен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен кушымта нигезендә расларга (кушымта).
2. Әлеге карар имзаланган көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р.Шакирҗанов

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның ____ __________ ____номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү максатыннан эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Буа муниципаль районы Башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау эшенең сыйфатын күтәрү, гражданнарның җәмәгатьчелек фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү формаларын һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау хисап чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре, шул исәптән язма рәвештә кергән мөрәҗәгатьләр, электрон документ формасында, Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелгән мөрәҗәгатьләр, шулай ук гражданнарны шәхси кабул итү барышында вәкаләтле затлар кабул иткән мөрәҗәгатьләр буенча башкарыла.

4. Килгән мөрәҗәгатьләр ел саен анализлана.

5. Анализ үткәргәндә кабул ителгән язма мөрәҗәгатьләр саны, электрон документ формасындагы мөрәҗәгатьләр, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, гражданнарны шәхси кабул итүдә кабул ителгән мөрәҗәгатьләр саны, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында мәгълүмат өйрәнелә.

6. Мөрәҗәгатьләр анализы Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә хисап чорыннан соң айның 15 нче көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.